**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Яңа Спас авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№20** **17.04.2026 ел**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Яңа Спас авыл җирлегенең Советы**
**2014 елның 28 февралендәге 90 номерлы карары**
**белән расланган Зәй муниципаль районының**
**Яңа Спас авыл җирлегендә муниципаль хезмәт**
**турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 26 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17.1 статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 26 февралендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Советы2014 елның 28 февралендәге 90 номерлы карары белән расланган Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 11 статьяның 3 өлешендәге 3 пунктының икенче абзацында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы (алга таба - «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон)» сүзләрен «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга (алга таба - «гавами хакимиятнең бердәм системасында жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон).»

1.2. 19 статьяда:

1) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы граждан, муниципаль хезмәткәр яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә, срокларда һәм формада тапшырыла.»;

2) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр "Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар

чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм аларның керемнәренә башка затлар чыгымнарының туры килүен тикшереп тору турында" Федераль закон) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан мондый мәгълүматларны тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча белешмәләр тапшырырга тиеш.»;

3) 3 өлештә «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга.;

4) 4 өлештә «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 5 өлештә «керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга,»;

6) 6 өлештә «муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «муниципаль хезмәткәргә әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;,»;

7) 7 өлештә «үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда каралган чыгымнар хакында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга»,»;

8) 8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне, мондый вазыйфаны биләүче зат әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә тапшыра.»;

9) 9 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. 20 статьяда:

1) 3 өлештә:

а) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр;»;

б) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.»

2) 7 өлештә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләрен «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 30 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктының «г» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президенты билгели торган исемлек буенча» сүзләрен төшереп калдырырга..

2. «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) да, җирлекнең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында әлеге карарны бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Спас авыл җирлеге
Советы башлыгы Танчук Н.В.